КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 июль г.Казань № 683

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел,

31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль, 568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 16 август, 737 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче; 2021 ел, 30 октябрь,1030 нчы; 2022 ел, 30 май, 499 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.10 пунктта:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) ялга китүче затларны алмаштырган чорда:

медицина персоналына (тәүлек буе эшли торган режимда эшләүче дәүләт оешмалары хезмәткәрләреннән тыш);

педагогик персоналга, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче персоналга (шул исәптән медицинага карамаган югары белеме булганнарга);

хуҗалыкта хезмәт күрсәтүче персоналга (котельный, ашханә хезмәткәрләре, автомобиль йөртүчеләр, җитештерү һәм хезмәт бүлмәләрен җыештыручылар, каравылчылар, гадәттән тыш һәм кичектергесез формада ашыгыч һәм амбулатор медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә җәлеп ителә торган башка хезмәткәрләр);»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) квалификация күтәрү курслары узган вакытта табиб һәм урта медицина персоналы вазифасын биләгән затларны, педагогик персоналны, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче персоналны (шул исәптән медицинага карамаган югары белеме булганнарны) алмаштырган чорда.»;

4 пунктчадан соң өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен түләү бу Нигезләмәнең 7.10 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән категорияләрдән дәүләт оешмасының эшләве өчен кирәк булган персонал өчен генә каралырга мөмкин.»;

4 пунктчадан соң унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$FOT_{zu}$ – квалификация күтәрү курслары узган вакытта табиб һәм урта медицина персоналы вазифасын биләгән затларны, педагогик персоналны, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче персоналны (шул исәптән

медицинага карамаган югары белеме булганнарны) алмаштыруга хезмәт өчен түләү фонды.»;

7.11 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT_{dpd} = \sum_{i_1=1}^{m_1} (KPO_{st_n} \times D_{gg} \times T_n \times (\frac{O_b}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d})) \times 0,5 + \sum_{i_1=1}^{m_1} (KPO_{sp_n} \times D_{gg} \times$$

$$\times\ T_n \times (\frac{O_b}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d})),»;$$

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«$m_1$ – төнлә белән кизү тору өчен җәлеп ителә торган хезмәткәрләр саны»; $i_1$

7.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.12. Эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә кизү торуга хезмәт өчен түләү фонды түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$FOT_{dpd} = \sum_{i_2=1}^{m_2} (KPO_{st_p} + KPO_{sp_p}) \times (\frac{O_b}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d}) \times D_{pg} \times$$

$$\times\ T_{pd} + \sum_{i_2=1}^{m_2} ((KPE_{ambp} \times (\frac{SZP}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d}) \times D_{pg} \times T_{pd}) +$$

$$+ (KPE_{ambp} \times (\frac{O_b}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d}) \times D_{pg} \times T_{pd})),$$

монда:

$FOT_{dpd}$ – эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә кизү торуга хезмәт өчен түләү фонды;

$KPO_{st_p}$ – медицина персоналының, эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә стационарда кизү тору өчен җәлеп ителә торган медицина персоналының (тәүлек буе эшли торган постлар булмаганда), сменалы график буенча эшләүче һәм расланган график кысаларында эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә кизү тору өчен җәлеп ителә торган педагогик персоналның, хуҗалыкта хезмәт күрсәтү персоналы вазифасын биләүче хезмәткәрләрнең һәм сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә шөгыльләнүче персоналның тәүлек буе эшли торган постларының планлаштырыла торган саны;

$KPO_{sp_p}$ – эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә кизү тору өчен җәлеп ителә торган ашыгыч медицина ярдәме бригадаларының планлаштырылган саны;

$O_b$ – дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең бу Нигезләмәнең 2 бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$D_{schrd}$ – бер айда эш көннәренең уртача саны;

$T_d$ – эш көненең озынлыгы;

$D_{pg}$ – бер елда эш көне булмаган бәйрәм көннәре саны;

$T_{pd}$ – эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә бер көнгә кизү тору сәгатьләре саны;

$KPE_{ambp}$ – гадәттән тыш яки кичектергесез формада амбулатор медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина персоналының, амбулатор наркологик ярдәм күрсәтү өчен медицина персоналының, педагогик персоналның, хуҗалыкта хезмәт күрсәтүче персонал вазифасын биләүче хезмәткәрләрнең һәм сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә шөгыльләнүче, графиктан тыш медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле рәвештә җәлеп ителүче персоналның эш көне булмаган бер бәйрәм көне исәбеннән планлаштырыла торган штат берәмлекләре саны;

SZP – бу Нигезләмәнең 3 – 5 бүлекләре нигезендә бер вазыйфага алына торган уртача хезмәт хакы;

$m_2$ – эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә кизү тору өчен җәлеп ителә торган хезмәткәрләр $i_2$ саны.»;

7.13 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT_{zo} = \sum_{i_3=1}^{m_3} (KPE_{zo} \times D_{go} \times (\frac{SZP}{D_{schrd}})),»;$$

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«$m_3$ – ялга китүче затларны алмаштыручы хезмәткәрләр саны.»;$i_3$

7.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.14. Квалификация күтәрү курслары узган вакытта табиб һәм урта медицина персоналы вазифасын биләгән затларны, педагогик персоналны, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче персоналны (шул исәптән медицинага карамаган югары белеме булганнарны) алмаштыруга хезмәт өчен түләү фонды түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$FOT_{zu}= \sum_{i_4=1}^{m_4} (KPE_{zu}\times D_{gu} \times (\frac{SZP}{D_{schrd}})),$$

монда:

$FOT_{zu}$ – квалификация күтәрү курслары узган вакытта табиб һәм урта медицина персоналы вазифасын биләгән затларны, педагогик персоналны, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче персоналны (шул исәптән медицинага карамаган югары белеме булганнарны) алмаштыруга хезмәт өчен түләү фонды;

$KPE_{zu}$ – квалификация күтәрү курслары узган вакытта табиб һәм урта медицина персоналы вазифасын биләгән затларны, педагогик персоналны, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче персоналны (шул исәптән медицинага карамаган югары белеме булганнарны) алмаштыру өчен штат берәмлекләренең планлаштырыла торган саны;

$D_{gu}$ – бер елга квалификация күтәрү курсларының уртача планлаштырылган көннәр саны;

SZP – бу Нигезләмәнең 3 – 5 бүлекләре нигезендә бер вазыйфага алына торган уртача хезмәт хакы;

$D_{schrd}$ – бер айда эш көннәренең уртача саны;

$m_4$ – квалификация күтәрү курсларын узган вакытта затларны алмаштыручы хезмәткәрләр $i_4$ саны.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин